ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 92-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Р. Гайзатуллин, А.Ю. Егоров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 92-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аппараты / Аппарат Государственного Совета Республики Татарстан
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 17 июле
№ 346-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Ю. Егоров, Р.Р. Гайзатуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы $6^2$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 93 (I өлеш), «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән» сүзләрен «Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 14 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2025 елның 14 декабрендә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 декабрендәге 475-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 475-ФЗ номерлы Федераль закон) үз көченә керә, аның белән берничә федераль законга гавами ресурслар белән эшләргә рөхсәт ителәчәк кредит оешмаларын сайлап алуның бердәм критериен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертелә. Кредит оешмаларын сайлап алуның универсаль критерие буларак илкүләм рейтинг шкаласы буенча бирелгән кредит рейтингы дәрәҗәсе билгеләнә.

475-ФЗ номерлы Федераль закон белән шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексына да үзгәрешләр кертелә, алар нигезендә капиталь ремонт фонды булдырыла торган махсус счет илкүләм рейтинг шкаласы буенча кредит рейтингы дәрәҗәсенә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә туры килә торган Россия кредит оешмаларында ачылырга мөмкин дип билгеләнә. Шундый ук таләпләр капиталь ремонт буенча региональ оператор тарафыннан Россия кредит оешмаларында ачыла торган счетларга, махсус счетларга карата билгеләнә.

Закон проекты белән шундый ук үзгәрешне «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына кертү тәкъдим ителә, бу вакытта капиталь ремонт буенча региональ оператор тарафыннан ачыла торган счетлар, махсус счетлар булган Россия кредит оешмаларына карата таләпләрне билгеләү өчен Россия Федерациясе Торак кодексына сылтама нормасы кулланыла.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.